Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР №IX-19

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 31 марты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шомарбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2021 елның 16 гыйнварында уздырылган ачык (гавами) тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 апрелендәге 6 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:
"капиталь төзелеш объектының мәгълүмати моделе (алга таба – мәгълүмати модель) – инженерлык эзләнүләрен башкару, архитектура-төзелеш проектлавын гамәлгә ашыру, төзелеш, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, эксплуатацияләү һәм (яки) капиталь төзелеш объектын сүтү этапларында электрон рәвештә формалаштырыла торган капиталь төзелеш объекты турында мәгълүматларның, документлар һәм материалларның үзара бәйләнгән җыелмасы";

1.2) 1 маддәнең 10 абзацында "заказ бирүченең" сүзләреннән соң " яки кайсыдыр ки 2017 елның 29 июлендәге "Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка)

төшкәндә гражданнарның – төзелешкә өлешләп кергән катнашучыларның хокукларын яклау буенча ачык-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 маддәсенә ярашлы рәвештә килешүләр нигезендә төзүченең функцияләрен тапшырдылар" сүзләре белән тулыландырырга;

1.3) 1 маддәне түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

"төзелеш, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, капиталь төзелеш объектларын сүтү, мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләрнең смета бәясе (алга таба – төзелешнең смета бәясе) – капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсе нигезендә архитектура-төзелеш проектлау, капиталь төзелеш объектын сүтүгә смета әзерләү һәм куллану этабында билгеләнергә тиешле исәп-хисап бәясе;";

1.4) 1 маддәнең унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"кызыл сызыклар – гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен билгели торган һәм территорияне планлаштыру документларында билгеләнергә, үзгәртелергә яисә бетерелергә тиешле линияләр;";

1.5) 1 маддәдә түбәндәге эчтәлектәге җөмләне төшереп калдырырга:

"Шәһәр төзелеше эшчәнлеге – территориаль планлаштыру, шәһәр төзелешен зоналаштыру, территорияне планлаштыру, архитектура-төзелеш проектлау, төзелеш, капиталь ремонт, реконструкция, капиталь төзелеш объектларын сүтү, биналарны, корылмаларны эксплуатацияләү, территорияләрне төзекләндерү рәвешендә гамәлгә ашырыла торган территорияләрне, шул исәптән шәһәрләрне һәм бүтән җирлекләрне үстерү буенча эшчәнлек";

1.6) 14 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтнамә бирү турындагы гариза "Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – электрон култамга белән имзаланган электрон документ) таләпләре нигезендә электрон култамга белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин";

1.7) 14 маддәнең 4 өлешендә "ун" сүзен "җиде эш" сүзләренә алмаштырырга;

1.8) 15 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Җир кишәрлекләре ияләре рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәтнамә сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы, әгәр мондый тайпылыш конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең бер яисә берничә иң чик параметрларын бер тапкыр ун процентка да артык булмаслык итеп үзгәртү максатларында зарури булса";

1.9) 26 маддәнең 7 өлешендәге 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Капиталь төзелеш объектларының максималь йөкләнешне күздә тоткан техник шартлары, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) сроклары һәм техник шартларның гамәлдә булу вакыты, шулай ук мондый тоташтыруга (технологик ялгауга) түләү турында мәгълүмат инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүче оешмалар

тарафыннан җиде эш көне дәвамында җирле үзидарә органнары, җир кишәрлекләре хуҗалары, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 1.1 һәм 1.2 өлешләре нигезендә проект документациясен әзерләүне тәэмин итүче затлар, яисә, әгәр Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнарда башкача каралмаган булса, территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруны күздә тотучы шартнамәләр төзелгән затлар сораулары буенча түләү алмыйча бирелә.";

1.10) 26 маддәнең 7 өлешендәге 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бирелгән техник шартларның гамәлдә булу срогы һәм мондый тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү кертү вакыты инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан кимендә өч елга яки территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне тормышка ашырганда кимендә биш елга билгеләнә, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан гайре.

Җир кишәрлегенә хокук иясе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 1.1 һәм 1.2 өлешләре нигезендә проект документларын әзерләүне тәэмин итүче зат бер ел дәвамында яисә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны күздә тоткан шартнамә төзелгән зат территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда мондый тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү турында техник шартлар һәм мәгълүмат бирелгән вакыттан алып өч ел дәвамында аларга бирелгән техник шартлар чикләрендә инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) өчен кирәкле йөкләнешне билгеләргә тиеш. Капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) срокларын һәм техник шартларның гамәлдә булу срогын, максималь йөкләнешне күздә тоткан техник шартларны тәкъдим итүче оешманың йөкләмәләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 1.1 һәм 1.2 өлешләре нигезендә проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка җир кишәрлеге бирү вакытыннан алып өч ел эчендә яисә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 1.1 һәм 1.2 өлешләре нигезендә проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка яисә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны күздә тотучы шартнамә төзелгән затка карата алар үзләренә бирелгән техник шартлар чикләрендә инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) өчен кирәкле булган йөкләнешнене билгеләмәсәләр һәм мондый тоташтыру (технологик ялгау) турында гариза бирмәсәләр туктатыла.";

1.11) 27 маддәнең 8 өлешендәге беренче абзацында "ун" сүзен "биш" сүзенә алмаштырырга;

1.12) 28 маддәнең 4 өлешендә "төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләүгә җаваплы зат, яки региональ оператор (төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә төзелешне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтны башкару очрагында)" сүзләрен "проектлауга" сүзләренә алмаштырырга, "проект документациясе" сүзләреннән соң "һәм (яисә) мәгълүмати модель (мәгълүмат

моделен булдыру һәм алып бару Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта)" сүзләрен өстәргә;

1.13) 28 маддәнең 10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге әлеге маддәнең 9 өлешендә күрсәтелгән объектларга карата гамәлгә ашырыла.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметы – капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү барышында эшләрнең үтәлүе һәм кулланыла торган төзелеш материалларының, шулай ук мондый эшләр нәтиҗәләренең проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә (энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь төзелеш объектларыннан гайре) һәм капиталь төзелеш объектын энергетика ресурсларыннан файдалану приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килүен тикшерү";

1.14) 28 маддәнең 5 өлешендә "Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә" сүзләрен "әлеге Кодекс нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 һәм 3.9 өлешләрендә күздә тотылган тәртиптә" сүзләренә алмаштырырга;

1.15) 26 маддәнең 10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Проект документациясе, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә аңа кертелгән үзгәрешләр төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләүгә җаваплы зат яисә региональ оператор тарафыннан раслана. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендә каралган очракларда төзүче яисә техник заказчы проект документациясе расланганчыга кадәр аны экспертизага җибәрә. Проект документлары, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 15.2 һәм 15.3 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, проект документациясенә уңай экспертиза булган очракта төзүче яисә техник заказчы тарафыннан раслана.";

1.16) 26 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 11-13 өлешләрне өстәргә:

"11. Төзүче яисә техник заказчы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.8 өлеше нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләрне проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җәлеп ителгән зат тарафыннан проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектлауны оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзасы булган зат тарафыннан тәкъдим ителгән раслау булганда расларга хокуклы.

12. Төзүче яисә техник заказчы тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.9 өлеше нигезендә проект документациясенә кертелгән үзгәрешләр расланган очракта, мондый үзгәрешләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.9 өлешендә күрсәтелгән һәм башкарма хакимият органы яисә әлеге проект документациясенә экспертиза уздырган оешма тарафыннан бирелгән очракта, әлеге проект документациясенә

кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау һәм (яисә) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.11 өлеше нигезендә бирелгән проект документациясенә экспертизаның уңай бәяләмәсе булганда төзүче яисә техник заказчы тарафыннан раслана.

13. Төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсен алганнан соң Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсенең 15.2 һәм 15.3 өлешләрендә күрсәтелгән үзгәрешләрне проект документациясенә кертү рөхсәт ителми шул чакта, әгәр мондый капиталь төзелеш объектын төзегәндә, реконструкцияләгәндә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган булса.";

1.17) 27 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә капиталь төзелеш объектларының проект документациясе һәм мондый проект документациясен әзерләү өчен башкарыла торган инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре дәүләт экспертизасы узарга тиеш, моңа түбәндәге капиталь төзелеш объектларының проект документациясе керми:

1) индивидуаль торак төзелеше объектлары, бакча йортлары;

2) катлар саны өчтән артмаган, уннан артмаган сандагы блоклардан торучы һәм һәрберсе бер гаилә яшәү өчен билгеләнгән берничә блоктан торган торак йортлар, күрше блоклар яки күрше блоклар белән уемсыз уртак диварга (гомуми диварга) ия, аерым җир кишәрлегендә урнашкан һәм гомуми файдаланудагы территориягә (блоклы төзелешле торак йортлар) чыгу юлы бар, мондый торак йортларны төзү яки реконструкцияләү Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә гамәлгә ашырыла;

3) катлар саны икедән артмаган аерым капиталь төзелеш объектлары, аларның гомуми мәйданы 1500 кв. метрдан артмый һәм алар гражданнар яшәве һәм җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аталмаган, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48.1 маддәсе нигезендә аеруча хәтәр, техник яктан катлаулы яки уникаль булган объектлардан гайре;

4) катлар саны икедән артмаган аерым торучы капиталь төзелеш объектлары, гомуми мәйданнары 1500 кв.м дан артык түгел, җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аталганнар һәм аларга санитар-саклау зоналары билгеләү таләп ителми яисә мондый объектлар урнашкан җир кишәрлекләре чикләрендә санитар-саклау зоналары билгеләнгән яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48.1 маддәсе нигезендә аеруча хәтәр, техник яктан катлаулы яки уникаль булган объектлардан тыш, мондый зоналарны билгеләү таләп ителә.

5) Россия Федерациясенең җир асты байлыклары турындагы законнары нигезендә әзерләнгән, килештерелгән һәм расланган файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты яки җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкару өчен башка проект документларында каралган бораулау скважиналары.

1.18) 27 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 3.1, 3.2, 3.3 пунктлары белән тулыландырырга:

“3.1 Капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән очракта, проект документларына экспертиза үткәрелми. Проект документларына экспертиза капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау өчен әзерләнгән проект документлары бүлекләренә карата үткәрелми.

3.2 Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза инженерлык эзләнүләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 2 өлешендә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының проект документациясен әзерләү өчен башкарылган очракта үткәрелми, шулай ук төзелеш, реконструкция өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән очракта.

3.3 Төзүче карары буенча проект документларына экспертиза проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсен алган проект документларына кертелгән үзгәрешләргә карата үткәрелмәскә мөмкин, әгәр мондый үзгәрешләр бер үк вакытта:

1)капиталь төзелеш объектының күтәреп торучы (терәк) төзелеш конструкцияләренә кагылмый, мондый конструкцияләрнең аерым элементларын шундый ук яисә мондый конструкцияләрнең күрсәткечләрен яхшырта торган элементларга алмаштырудан тыш;

2) линияле объектлар эшләвенең классы, категориясе һәм (яки) башта билгеләнгән күрсәткечләренең үзгәрүенә китермиләр;

3) техник регламентлар таләпләренең, санитар-эпидемиологик таләпләр, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләр, мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы таләпләре, атом энергиясен имин файдалануга таләпләр, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләре, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә таләпләрнең, объектның террорчылыкка каршы саклануы таләпләрен бозуга китермиләр;

4) проектлауга төзүче яисә техник заказ бирүченең биремнәренә, шулай ук инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә туры килә;

5) дәүләт (муниципаль) милкенең капиталь төзелеш объектына карата билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән капиталь салулар башкаруга бюджет ассигнованиеләре бирү турындагы карарда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджет акчалары хисабына башкарыла торган капиталь төзелеш объектын төзү (реконструкцияләү) бәясенә туры килә.

1.19) 27 маддәнең 5 өлеше 3 пунктындагы 1 абзацта “проект” сүзен “Россия Федерациясе шәһәр төзелеше Кодексының 48 маддәсендәге 15, 15.2 һәм 15.3 өлешләре нигезендә расланган проект” сүзләренә алмаштырырга;

29 маддәнең 4 өлешендә “ун эш көне эчендә” сүзләрен “биш эш көне эчендә” сүзләренә алмаштырырга;

1.20) 29 маддәнең 5 өлешендәге 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“- капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәтнамәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 маддәсенең 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объектының мәйданын үзгәртү очракларыннан гайре”;

1.21) 29 маддәнең 5 өлешендәге 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“-төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объекты параметрларының проект документациясенә туры килмәве, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 маддәсенең 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объектының мәйданын үзгәртү очракларыннан гайре”;

1.22) 29 маддәнең 3 өлешендәге 9 пунктында “проект документациясе” сүзләреннән соң “(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен кертеп)” сүзләрен өстәргә.

1.24) 30 маддәнең 12 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларның дәвамлылыгы мондый проект басылып чыккан (игълан ителгән) көннән башлап кимендә бер айны тәшкил итә һәм өч айдан да артык түгел.”

1.23) 32 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Территориаль зоналар чикләре һәр җир кишәрлегенең бары тик бер территориаль зонага гына туры килү таләбенә җавап бирергә тиеш, чикләре җир законнары нигезендә территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән гайре.”

1.24) 36 маддәнең 8 өлешендәге 20 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“пестицидлар һәм агрохимикатларны саклау (яр буе саклау полосалары чикләреннән читтә диңгез портлары территорияләрендә махсуслаштырылган саклагычларда агрохимикатлар саклаудан гайре), пестицидлар һәм агрохимикатлар куллану”

1.25) 36 маддәнең 8 өлешендәге 31 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- “автозаправка станцияләрен, ягулык-майлау материаллары складларын (автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары портлар, эчке су юллары инфраструктурасы территорияләрендә, шул исәптән аз үлчәмле суднолар кую өчен базалар (корылмалар) территорияләрендә, федераль иминлек хезмәте органнары объектларында урнаштырылган очраклардан гайре), транспорт чараларын техник карау һәм ремонтлау өчен кулланыла торган техник хезмәт күрсәтү станцияләрен төзү һәм реконструкцияләү, транспорт чараларын юуны гамәлгә ашыру.”;

1.26) 36 маддәнең 8 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 39 абзацны өстәргә::

“-су объектларын һәм алар янәшәсендәге территорияләрне нефть һәм нефть продуктларын агызудан һәм тирә-юньгә башка тискәре йогынтыдан саклауны тәэмин итә торган корылмалар”;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт һәм Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов